**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БИЕКТАУ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**МҮЛМӘ**
**АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422731, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Мүлмә авылы, Үзәк ур., 46а

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**МУЛЬМИНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**ВЫСОКОГОРСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422731, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с. Мульма, ул. Центральная, 46а

тел./факс 8(84365) 70-2-03, e-mail: Mulm.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**4 сентябрь 2019 ел** **№ 21**

**“Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге территориясендә капиталь төзелеш объектын планлаштырыла торган сүтү турында хәбәрнамә, капиталь төзелеш объектын сүтү тәмамлану турында хәбәрнамә кабул итү” муниципаль хезмәтен күрсәтү буенча Административ регламентны раслау турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”, 2003 елның 6 нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”, 2010 елның 7 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы белән эш йөртеп, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Теркәлгән “Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә капиталь төзелеш объектын планлаштырыла торган сүтү турында хәбәрнамә, капиталь төзелеш объектын сүтү тәмамлану турында хәбәрнамә кабул итү” муниципаль хезмәтен күрсәтү буенча Административ регламентны расларга.
2. Әлеге карарны Мүлмә авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarsta№.ru һәм Биектау муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлекләре бүлегендә Интернет челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarsta№.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
3. Әлеге карар бастырып чыгарылган (халыкка җиткерелгән) көннән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Мүлмә авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе Л.Р. Зиннатуллин

Кушымта

РАСЛАНГАН

ТР Биектау муниципаль районы
Мүлмә авыл җирлеге
Башкарма комитеты карары белән
04.09.2019 № 21

**“Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә капиталь төзелеш объектын планлаштырыла торган сүтү турында хәбәрнамә, капиталь төзелеш объектын сүтү тәмамлану турында хәбәрнамә кабул итү” муниципаль хезмәтен күрсәтү буенча**

# АДМИНИСТРАТИВ РЕГЛАМЕНТ

## I. Гомуми нигезләмәләр

### 1 бүлек. Җайга салу предметы

1. “Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге территориясендә капиталь төзелеш объектын планлаштырыла торган сүтү турында хәбәрнамә, капиталь төзелеш объектын сүтү тәмамлану турында хәбәрнамә кабул итү” муниципаль хезмәтен күрсәтү буенча Административ регламенты (алга таба – Административ регламент, муниципаль хезмәт күрсәтү) Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге территориясендә капиталь төзелеш объектын планлаштырыла торган сүтү һәм сүтү тәмамлану турында хәбәрнамә кабул итү вакытында Мүлмә авыл җирлеге Башкарма комитеты вазыйфаи затларының административ процедураларының һәм административ гамәлләренең срокларын һәм эзлеклелеген билгели (алга таба – муниципаль хезмәт).

### 2 бүлек. Гариза бирүчеләр даирәсе

2. Муниципаль хезмәт алу артыннан муниципаль хезмәт күрсәтү турында язма яки электрон формада чагылдырылган сорату белән мөрәҗәгать итәргә мөмкиннәр: сүтүне тормышка ашыруга подряд шартнамәсе төзегән, төзүче яисә техник заказчы булган шәхси эшмәкәрләр яки юридик затлар (алга таба – гариза бирүчеләр).

### 3 бүлек. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында мәгълүмат җиткерү тәртибенә таләпләр

3. Башкарма комитетның урнашкан урыны, эш графигы, белешмә өчен телефоннары, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникацияләр сайтында рәсми сайт адреслары (алга таба – Интернет челтәре), электрон почта турында мәгълүматлар урнаштырыла:

4. Муниципаль хезмәт Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан тәкъдим ителә (алга таба – Башкарма комитет).

5. Башкарма комитетның урнашкан урыны: 422731, Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Мүлмә авылы, Үзәк урам, 46а йорты.

6. Эш графигы:

дүшәмбе - җомга: 8.00дән 17.00гә кадәр.

Шимбә, якшәмбе – ял көннәре.

Ял итү һәм туклану өчен тәнәфес вакыты эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре белән билгеләнә.

Белешмәләр өчен телефон (884365) 70-2-03.

Керү шәхесне ачыклаучы документлар буенча.

7. Муниципаль районның “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникацияләр сайтында (алга таба – “Интернет” челтәре) рәсми сайты: http://vysokaya-gora.tatar.ru. Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат турыдан-туры Башкарма комитеттан телефон, почта, шул исәптән электрон почта, Башкарма комитетның мәгълүмати стендларында урнаштыру, КФҮ аркылы, шулай ук интернет-сайтта, федераль дәүләт мәгълүмати системасында “Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы” Интернет челтәрендә www.gosuslugi.ru (алга таба – Бердәм портал), Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат системасында “Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы” Интернет челтәрендә http://uslugi. tatar.ru/ адресы буенча (алга таба – Портал) урнаштырып алынырга мөмкин.

8. Муниципаль хезмәт күрсәтү барышы һәм тәртибе турында мәгълүмат җиткерү телефон элемтәсе аркылы 10 минуттан да артык булмаска тиеш. Шалтыратуны кабул иткән белгеч, үзенең вазыйфасын, фамилиясен, исемен, әтисенең исемен атарга тиеш.

9. Шәхси телдән мөрәҗәгать иткәндә муниципаль хезмәт күрсәтү барышы һәм тәртибе турында мәгълүмат җиткерү 15 минуттан да артмаска тиеш.

10. Язмача мөрәҗәгатькә җавап ачык, төгәл һәм аңлаешлы формада, турыдан-туры башкаручының фамилиясен, исемен һәм телефон номерын күрсәтеп тәкъдим ителә. Җавап язмача формада яки электрон почта аша (язмача мөрәҗәгатьтәге яки гражданинның мөрәҗәгать итү тәртибендәге җавапны тапшыру ысулыннан чыгып) җибәрелә. Җавап язмача мөрәҗәгать теркәлгәннән соң, утыз көн дәвамында җибәрелә.

11. Электрон почта аша мәгълүмат җиткергәндә билгеле җавап, мөрәҗәгать кергән моменттан 30 көннән дә артмаган срокта гариза бирүченең электрон почтасына җибәрелә.

12. Телефон аша мәгълүмат җиткергәндә: яисә гариза бирүчеләрең шәхси мөрәҗәгате очрагында, кергән мөрәҗәгать нигезендә, түбәндәге мәсьәләләр буенча мәгълүмат җиткерергә:

1) делопроизводство системасында теркәлгән кертелгән номер турында мәгълүмат;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча норматив хокукый актлар турында мәгълүматлар;

3) муниципаль хезмәтне алу өчен кирәкле документларның исемлеге.

## II өлеш. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

### 4 бүлек. Муниципаль хезмәт күрсәтү исеме

13. Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге территориясендә капиталь төзелеш объектын планлаштырыла торган сүтү турында хәбәрнамә, капиталь төзелеш объектын сүтү тәмамлану турында хәбәрнамә кабул итү.

### 5 бүлек. Муниципаль хезмәт күрсәтүгә вәкаләтле органның исеме

14. Муниципаль хезмәт Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан тәкъдим ителә (алга таба – Башкарма комитет).

Башкарма комитет гариза бирүчеләрдән муниципаль хезмәт алу өчен кирәкле һәм башка органнарга һәм оешмаларга мөрәҗәгать итү белән бәйле гамәлләрне тормышка ашыруны таләп итәргә, шул исәптән килешенгәннәрен дә, күрсәтелергә кирәкле һәм тиешле булган хезмәтләр исемлегенә кергән хезмәтләрдән һәм муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрдән, Биектау Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге җирде үзидарәсе тарафыннан тәкъдим ителә торган муниципаль хезмәт күрсәтүләрдән кала.

### 6 бүлек. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе

15. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең ахыргы нәтиҗәсе булып тора:

1) капиталь төзелеш объектын планлаштырыла торган сүтү турында хәбәрнамә, капиталь төзелеш объектын сүтү тәмамлану турында хәбәрнамә (алга таба – хәбәрнамәләр) һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итү мәгълүмати системасындагы документларны урнаштыру;

2) әлеге урнаштыру турында төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеге органына хәбәрнамә җиткерү.

### 7 бүлек. Муниципаль хезмәт күрсәтү сроклары

16. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы, хәбәрнамә каблу иткән көннән 7 көннән дә артмаган срокны тәшкил итә.

### 8 бүлек. Муниципаль хезмәт күрсәтү белән бәйле элемтәләр белән килеп туучы мөнәсәбәтләрне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге

17. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге хокукый актлар нигезендә тормышка ашырыла:

1) Россия Федерациясе Конституциясе // Российская газеты, 1993 ел, 25 декабрь, №237

2) “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”, 2003 елның 6 нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон //

"Российская газета" 2003, 8 октябрь, № 202;

3) “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”, 2010 елның 7 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон // "Российская газета", 2010 ел, 30 июль, № 168;

4) Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы ("Российская газета", 30.12.2004, № 290, Россия Федерациясе законнары Җыелмасы, 03.01.2005 № 1,ст.16, "Парламентская газета", 14.01.2005, №№ 5-6);

5) “Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексын гамәлгә кертү турында”, 2004 елның 29 нчы декабрендәге 191-ФЗ номерлы Федераль закон ("Российская газета", 30.12.2004, № 290, Россия Федерациясе законнары Җыелмасы, 03.01.2005 № 1 (1 бүлек) "Парламентская газета", 14.01.2005, №№ 5-6)

6) “Шәхси мәгълүматлар турында”, 2006 елның 27 нче июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнары Җыелмасы, 2005 ел № 31 (1 бүлек 3451 ст.)

7) “Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау турында” 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнары Җыелмасы, 2006 ел № 19 ( 2060 ст.)

8) “Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында” 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы (алга таба – ТРның 16 номерлы Законы) (“Республика Татарстан” 17.05.2003, № 99-100);

9) 2015 елның 24 ноябрендәге 17 номерлы Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге Советы Карары белән кабул ителгән “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы (Советның 10.10.2016 №50, 05.10.2017 №86, 02.04.2018 №104, 13.09.2018 №120 Карарлары редакциясендә (алга таба – Устав);

10) 2019 елның 27 июнендәге 158 номерлы Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге Советы Карары белән кабул ителгән Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге башкарма комитеты турында Нигезләмә (алга таба – Башкарма комитет турында Нигезләмә);

11) 2010 елның 1 нче декабрендәге 5 номерлы Башкарма комитет җитәкчесе тарафыннан расланган Башкарма комитетның эчке хезмәт тәртибе Кагыйдәләре белән (алга таба – Кагыйдәләр).

## 9 бүлек. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен тиешле һәм мәҗбүри булган документларның тулы исемлеге

18. Капиталь төзелеш объектын сүтү максатларыннан, төзүче яки техник заказчы кәгазьдә Башкарма комитетка шәхси мөрәҗәгать итеп, шул исәптән күп функцияле үзәк аркылы тапшыра, яисә күрсәтелгән органнарга почта аркылы тапшыру турында хәбәр белән яки дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталы ярдәмендә капиталь төзелеш объектын сүтү турында хәбәрнамә җибәрә. Күрсәтелгән хәбәрнамәдә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

1) төзүченең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булган очракта), яшәү урыны, шәхесен ачыклаучы документның реквизитлары (физик зат өчен);

2) төзүченең яки техник заказчының исеме һәм урнашкан урыны (юридик затлар өчен), шулай ук юридик затларның бердәм дәүләт реестрында юридик затның дәүләт теркәве турында дәүләт теркәве номеры һәм салым түләүченең идентификацион номеры, гариза бирүче булып чит ил юридик заты булган очрактан кала;

3) җир кишәрлегенең кадастр номеры (булган очракта), җир кишәрлегенең адресы яки урнашкан урынының тасвирламасы;

4) төзүченең җир кишәрлегенә хокукы турында мәгълүматлар, шулай ук башка затларның җир кишәрлегенә хокуклары булуы турында мәгълүматлар (андый затлар булган очракта);

5) төзүченең сүтелергә тиешле капиталь төзелеш объектына хокуклары турында мәгълүматлар, шулай ук башка затларның сүтелергә тиешле капиталь төзелеш объектына хокуклары булу турында мәгълүматлар (андый затлар булган очракта);

6) капиталь төзелеш объектын сүтү турында яисә үзлектән төзелгән корылманы сүтү буенча йөкләмәләр булуы турында, җир законнары нигезендә, судның яки җирле үзидарә органының мәгълүматлары (андый карарлар яисә йөкләмәләр булган очракта);

7) төзүче яки техник заказчы белән элемтәгә керү өчен почта адресы һәм (яки) электрон почта адресы.

19. Капиталь төзелеш объектын планлаштырылган сүтү турында хәбәрнамәгә, түбәндәге документлар беркетелә, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясы 17 бүлеге 1-3 пунктларында күрсәтелгән объектлардан кала:

1) капиталь төзелеш объектын тикшерү нәтиҗәләре һәм материаллары;

2) капиталь төзелеш объектын сүтү буенча эшләрне оештыру проекты.

20. Төзүче яки техник заказчы бетерелгән капиталь төзелеш объекты булган җир кишәрлеге урнашу урыны буенча Башкарма комитетка шәхси мөрәҗәгать аркылы кәгазьдә тапшыра, шул исәптән күпфункцияле үзәк аркылы, яисә билгеле җирле үзидарә органыны почта яки дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы аркылы капиталь төзелеш объектын сүтү тәмамлану турында хәбәрнамә җибәрә.

21. Капиталь төзелеш объектын планлаштырылган сүтү турында хәбәрнамә, капиталь төзелеш объектын сүтүне тәмамлау турында хәбәрнамә формасы төзелеш, архитектура, шәһәр төзелеше өлкәсендә норматив-хокукый җайга салуны эшләп чыгару һәм тормышка ашыру буенча функцияләрне тормышка ашыручы федераль башкарма хакимият органнары тарафыннан раслана.

## 10 бүлек. Төзүче тарафыннан мөстәкыйль рәвештә тәкъдим ителергә тиешле муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә, документларның тулы исемлеге

22. Төзүче тарафыннан мөстәкыйль рәвештә тәкъдим ителергә тиешле муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә, әлеге административ регламентның 19 пункты нигезендә, документларның тулы исемлеге:

1) капиталь төзелеш объектын планлаштырылган сүтү турында хәбәрнамә;

2) капиталь төзелеш объектын тикшерү нәтиҗәләре һәм материаллары;

3) капиталь төзелеш объектын сүтү буенча эшләрне оештыру проекты.

23. Төзүче тарафыннан мөстәкыйль рәвештә тәкъдим ителергә тиешле муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә, әлеге административ регламентның 20 пункты нигезендә, документларның тулы исемлеге:

- капиталь төзелеш объектын сүтүне тәмамлау турында хәбәрнамә.

## 11 бүлек. Муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы башка органнар карамагында булган һәм гариза бирүче мөстәкыйль рәвештә тәкъдим итәргә тиешле, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

24. Муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы башка органнар карамагында булган муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге.

Гариза бирүчедән таләп итәргә тыела:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү белән бәйле рәвештә килеп туа торган мөнәсәбәтләрне җайга салучы норматив хокукый актлар белән аларны тәкъдим итү яки тормышка ашыру күз алдында тотылмаган документларны һәм мәгълүматларны тәкъдим итү яки гамәлләрне тормышка ашыру;

2) документлар һәм мәгълүматлар тәкъдим итү, шул исәптән Гариза бирүче тарафыннан хезмәт күрсәтүдә катнашучы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү турында 210-ФЗ номерлы Законның 1 статьясы 1 бүлеге, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль берәмлекнең муниципаль норматив хокукый актлары белән күз алдында тотылган, 210-ФЗ номерлы Законның 7 статьясы 6 бүлеге белән билгеләнгән документлардан кала, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен дәүләт хезмәтен күрсәтүче органнар, муниципаль хезмәт күрсәтүче органнар яисә дәүләт органнарына яки җирле үзидарә органнарына ведомтво карамагында булган органнар карамагында булган, түләү кертүне раслаучы документларны һәм мәгълүматларны тәкъдим итү;

3) муниципаль хезмәтне алу өчен кирәкле гамәлләр, шул исәптән килештерүләрне тормышка ашыру, башка дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына, оешмаларга 210-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы 1 бүлегендә күрсәтелгән исемлеккә кертелгән андый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсендә хезмәтләр алу һәм документлар һәм мәгълүмат алудан кала;

4) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган документларны кабул иткәндә беренчел кире какканда документларның һәм мәгълүматларның булмавы һәм (яки) тулы булмавы күрсәтелмәсә, яисә муниципаль хезмәт күрсәтү, түбәндәге очраклардан кала:

а) муниципаль хезмәт күрсәтүгә кагылган норматив хокукый актларның муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза беренчел тапшырылганнан соң үзгәрүе;

б) Гариза бирүче муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны беренчел кире какканнан соң тапшырган муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризада һәм документларда хаталар булуы, яисә муниципаль хезмәтне күрсәтүдә һәм элек тәкъдим ителгән документлар комплектына кертелмәве;

в) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле, муниципаль хезмәт күрсәтүдә документларның гамәлдә булу срогы чыгу яки дкументларны кабул итүдән беренчел баш тартудан соң мәгълүматлар үзгәрү;

г) Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле, яисә муниципаль хезмәт күрсәтүдә документларны кабул итүне беренчел кире какканда, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфа затының, муниципаль хезмәткәрнең, КФҮ хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1.1 бүлеге белән күз адында тотылган оешма хезмәткәрләренең ялгыш яки хокукка каршы гамәлләрен (гамәл кылмауларын) документаль раслаучы факт (билгеләр) ачыклану, бу хакта язмача формада муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, КФҮ җитәкчесенең, яисә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1.1 бүлеге белән күз адында тотылган оешма җитәкчесе имзачы белән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән беренчел баш тартканда Гариза бирүчегә хәбәрнамә җибәрелә, шулай ук китерлегән уңайсызлыклар өчен гафу сорала.

### 12 бүлек. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдә нигез булган тулы исемлек

25. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдә нигезләр юк.

### 13 бүлек. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору яки баш тартуга нигезләрнең тулы исемлеге

26. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.

27. Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге:

1) гариза бирүченең вәкилендә муниципаль хезмәт күрсәтүгә вәкаләтләр булмавы;

2) гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтү турында, аны күрсәтү вәкаләтле орган тарафыннан тормышка ашырылмый торган мөрәҗәгате; гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату турында үтенеч белән мөрәҗәгать итүе (язмача формада);

3) гариза бирүченең вәкаләтле орган соратуы буенча административ регламентның 22 пункты (19 пункт нигезендә) яки 23 пункты (20 пункт нигезендә) күз алдында тотылган документларны тәкъдим итмәве.

## 14 бүлек. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен дәүләт пошлинасы яки башка төр түләү алыну тәртибе, күләме һәм нигезләре

28. Муниципаль хезмәт күрсәткән өчен түләү алынмый.

## 15 бүлек. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорату биргәндә һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтеп торуның максималь вакыты

29. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында хәбәрнамәләр биргәндә һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтеп торуның максималь вакыты 15 минутны тәшкил итә.

## 16 бүлек. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында хәбәрнамәләрне теркәү срогы һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада

30. Кәгазьдә килгән хәбәрнамәләр һәм аларга беркетелгән документлар, бер эш көне дәвамында Башкарма комитетның электрон документ әйләнеше һәм делопроизводство системасы мәгълүматлар базасында тәртип номеры һәм хәбәрнамә тапшыруның датасын күрсәтеп теркәлә.

31. Электрон формада кергән хәбәрнамәләр Башкарма комитетның электрон документ әйләнеше һәм делопроизводство системасы мәгълүматлар базасында планлаштырыла торган төзелеш турында хәбәрнамәләр кергән көннән бер эш көненнән дә соңга калмыйча теркәләр.

32. Электрон формадагы хәбәрнамә эш көне тәмамланганнан соң кергән очракта, аны теркәү хәбәрнамә кергән көннән соң киүче икенче эш көненнән дә соңга калмыйча теркәлә. Электрон формадагы хәбәрнамәләр ял көннәрендә яки эш көннәре булмаган бәйрәм көннәрендә кергән очракта, аны теркәү аның артыннан килүче беренче эш көнендә тормышка ашырыла.

33. Хәбәрнамәләрне һәм аңа беркетелә торган документларны электрон формада “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтәр күрсәтүнең бердәм порталы” федераль дәүләт мәгълүмат системасы www.gosuslugi.ru электрон адресы аркылы (алга таба – Бердәм портал) һәм (яки) “Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы” Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы http://uslugi.tatar.ru/ электрон адресы (алга таба – Төбәк порталы) аркылы тапшыру рөхсәт ителә.

КФҮкә килгән хәбәрнамәләр Башкарма комитетның электрон документ әйләнеше һәм делопроизводство системасы мәгълүматлар базасында теркәлә.

## 17 бүлек. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, көтү залларына, муниципаль хезмәт күрсәтү турында хәбәрнамәләр тутыру өчен урыннарга, аларны тутыру үрнәкләр ебелән мәгълүмати стендларга һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлегенә таләпләр

34. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен бина Башкарма комитет бинасында гариза бирүчеләр өчен җәмәгать транспорты тукталышыннан җәяүләп керү мөмкинлеге булган арада урнаштырыла.

35. Инвалидларга муниципаль хезмәт күрсәткән вакытта “Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында” Федераль законның 15 статьясы таләпләре нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтүне тоткарлыксыз алу өчен шартлар белән тәэмин ителгән.

36. Бина янындагы территориядә автотранспорт чараларын кую өчен урыннар каралган. Гражданнарга парковка урыннарына керү түләүсез булып тора.

37. Бинага керү Башкарма комитет исеме язылган элмә такта белән җиһазландырылган.

38. Көтү урыннары һәм гаризалар тутыру өчен урыннар уңайлы шартларга туры килә, урнныдыклар (кәнәфи секцияләре) яки эскәмияләр (банкеткалар) белән җиһазландырылган. Көтү урыннары саны факттагы йөкләнеш һәм аларны муниципаль хезмәт күрсәтелә торган бинада урнаштыру мөмкинлегеннән чыгып билгеләнә, 3 урыннан да ким булмаска тиеш.

39. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган бинада гражданнар өчен һәркем куллана алырлык иҗтимагый куллану урыннарын (бәдрәф) һәм өске киемнәрне саклау (гардероб) урыннары белән җиһазландыру күз алдында тотыла.

40. Муниципаль хезмәт Башкарма комитет белгече тарафыннан, бинада урнашкан бүлмәләрдә күрсәтелә.

41. Муниципаль хезмәт күрсәтүче Башкарма комитет белгеченең эш урыны белешмә өчен мәгълүматларны вакытында һәм тулы күләмдә алырга мөмкинлек һәм муниципаль хезмәтне бирүне тулы күләмдә алуны оештыру өчен хокукый һәм мәгълүмати базасына керү мөмкинлеге булган шәхси компьютер, бастуручы һәм күчермәләрен алучы җайланмалар белән җиһазландырыла, кәгазь, чыгым материаллары һәм канцелярия кирәк-яраклары муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәк күләмдә бүлеп бирелә.

42. Гариза бирүче турында мәгълүматларның конфиденциальлеген тәэмин итү максатыннан, бер белгеч тарафыннан бер үк вакытта ике һәм аннан да күбрәк гариза бирүчегә консультацияләр бирү һәм (яки) кабул итү рөхсәт ителми.

43. Гариза бирүчеләрне кабул итү өчен билгеләнгән биналар түбәндәге мәгълүмат урнаштырылган мәгълүмати стендлар белән җиһазландырылалар:

1) Башкарма комитетның адресы, телефон номерлары, эш сәгатьләре, Башкарма комитетның, КФҮ электрон почтасы;

2) гражданнарны Мүлмә авыл җирлеге Башлыгы, Мүлмә авыл җирлеге Башлыгы урынбасарлары, Башкарма комитет белгечләре тарафыннан кабул итү графигы;

3) әлеге административ регламентның тексты;

4) муниципаль хезмәт күрсәтү блок-схемасы;

5) төзелеш тәмамлану турынңа хәбәрнамә үрнәге;

6) "Интернет" челтәрендә Башкарма комитетның рәсми сайты адресы;

7) Бердәм портал, Төбәк порталы адресы;

8) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге;

9) Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләрнең исемлеге.

## 18 бүлек. Муниципаль хезмәтләрне алырга мөмкин булуы һәм сыйфаты күрсәткечләре

44. Муниципаль хезмәтләрне алырга мөмкин булуы һәм сыйфаты күрсәткечләре булып торалар:

1) “Интернет” челтәрен кулланып муниципаль хезмәт күрсәтү очракларының өлеше (күрсәткеч “Интернет” челтәрен кулланып, муниципаль хезмәт алган кулланучыларның муниципаль хезмәт күрсәтелгән гариза бирүчеләрнең гомуми санын 100 процентка тапкырлаган чагыштырмасы буларак ачыклана);

2) билгеләнгән вакытта муниципаль хезмәт күрсәтү очракларының өлеше (күрсәткеч билгеләнгән вакытта муниципаль хезмәт күрсәтү очраклары санының, муниципаль хезмәт күрсәтелгән гариза бирүчеләрнең гомуми санын 100 процентка тапкырлаган чагыштырмасы буларак ачыклана);

3) муниципаль хезмәт күрсәтелгән гариза бирүчеләрнең гомуми санына дәлилләнгән шикаятьләрнең өлеше (күрсәткеч муниципаль хезмәт күрсәтелгән гариза бирүчеләрнең гомуми санына дәлилләнгән шикаятьләрнең санының муниципаль хезмәт күрсәтелгән гариза бирүчеләрнең гомуми санын 100 процентка тапкырлаган чагыштырмасы буларак ачыклана).

## 19 бүлек. Муниципаль хезмәтне электрон формада тәкъдим итү үзенчәлекләрен исәпкә алучы таләпләр

45. Гариза бирүчеләргә муниципаль хезмәтне алу өчен муниципаль хезмәт күрсәтү өчен электрон документ формасында, билгеле электрон имза белән имзаланган, Бердәм портал һәм (яки) Төбәк порталы аркылы кирәкле хәбәрнамәләрне һәм аларга беркетеләгән документларны тәкъдим итү мөмкинлеге бирелә (аларда булган мәгълүматлар).

Тәкъдим ителгән электрон документларның сыйфаты документ текстын тулы күләмдә укырга мөмкинлек бирергә һәм аның реквизитларын танырга мөмкин булырга тиеш.

46. Муниципаль хезмәтне төзүчегә электрон формада Бердәм портал һәм (яки) Төбәк порталы аркылы тәкъдим иткәндә тәэмин ителә :

1) муниципаль хезмәт алу тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат алу;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү турында электрон формадагы хәбәрнамәләрне тутыру юлы белән сорату формалаштыру;

3) муниципаль хезмәт алу өчен кирәкле булган хәбәрнамәләрне һәм документларны “Бер тәрәзә хезмәте” бүлеге хезмәткәре тарафыннан кабул итү һәм теркәү;

4) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алу;

5) хәбәрнамәләрне карау барышы турында мәгълүматлар алу;

6) муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфатына бәя бирүне тормышка ашыру;

7) Башкарма комитет, Башкарма комитет вазыйфаи затының карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү.

47. Төзүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе сыйфатында документларны кәгазь формада алуны тәэмин итү каралган.

48. Хәбәрнамәләрне һәм документларны КФҮ аша тәкъдим иткәндә, әлеге административ регламентның 16 пунктында күрсәтелгән муниципаль хезмәт күрсәтү срогы, әлеге административ регламентның 19 пунктында күрсәтелгән хәбәрнамәне һәм документларны КФҮ Башкарма комитетка тапшырган көннән санала.

Хәбәрнамәләр һәм беркетелгән документлар төзүче тарафыннан (төзүченең вәкиле) шәхсән үзе КФҮ аркылы тәкъдим итсә, төзүчегә хәбәрнамәләр һәм документлар алу турында расписка бирелә.

Гаризада муниципаль хезмәтнең нәтиҗәсен КФҮ аркылы тәкъдим итү күрсәтелгән булса, Башкарма комитет хәбәрнамәләрне һәм документларны тәкъдим итү урыны буенча, документларны төзүчегә бирү өчен КФҮгә әлеге административ регламентның 16 пунктында билгеләнгән срок чыкканнан соң килә торган эш көненнән дә соңга калмыйча тапшыруны тәэмин итә.

“Бер тәрәзә” принцибы буенча тәкъдим ителә торган муниципаль хезмәтнең территориаль алу мөмкинлеген арттыру максатыннан, КФҮ “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” Федераль законның 16 статьясы 1.1 бүлеге белән күз алдында тотылган оешмаларны җәлеп итәргә хокуклы.

## III өлеш. Административ процедераларның составы, эзлеклелеге һәм башкару вакыты, аларны башкару тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон формада башкару үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны КФҮларда башкару үзенчәлекләре

### 20 бүлек. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ процедуралар составы

49. Муниципаль хезмәт күрсәтү үз эченә түбәндәге административ процедураларны ала:

1) капиталь төзелеш объектын планлаштырылган сүтү турында яки сүтүне тәмамлау турында хәбәрнамә һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

2) “Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрне оештыру турында” 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча ведомствоара соратулар формалаштыру һәм җибәрү (документлар гариза бирүченең шәхсән үзе тарафыннан бирелмәгән очракта);

3) муниципаль хезмәт күрсәтү турында карар кабул итү;

4) муниципаль хезмәт нәтиҗәсен формалаштыру һәм гариза бирүчегә бирү.

50. Муниципаль хезмәт күрсәткәндә админстратив процедуралара эзлеклелеге блок-схемада күрсәтелгән (әлеге административ регламентка 1 нче кушымта).

### 21 бүлек. Муниципаль хезмәт күрсәткәндә административ процедураларны тормышка ашыру эзлеклелеге

§1. Хәбәрнамәләрне һәм аларга беркетелгән документларны кабул итү һәм теркәү

51. Административ процедураны башлау өчен нигез булып административ регламентның 18 пунктында күрсәтелгән капиталь төзелеш объектын планлаштырылган сүтү турында хәбәрнамә һәм документларның яки муниципаль хезмәт күрсәтү турында 20 пунктта күрсәтелгән капиталь төзелеш объектын сүтү тәмамлану турында хәбәрнамә һәм документларның Башкарма комитетка, КФҮгә, Бердәм порталга һәм (яки) Төбзк порталына керүе тора.

52. Язмача хәбәрнамәләр һәм документлар Башкарма комитетка яки КФҮкә кертелгән вакытта, административ процедураларны башкару өчен җаваплы булып Башкарма комитет белгече тра.

53. Башкарма комитет белгече хәбәрнамәләрнең тиешенчә рәсмиләштерелүен һәм аларга беркетелгән документларның булуын, гариза бирүченең шәхесен ачыклаучы документ (әгәр дә хәбәрнамә төзүче тарафыннан шәхсән бирелгән булса) булуын тикшерә. Әгәр дә гариза бирүче исеменнән гариза бирүченең вәкиле эш итсә, Башкарма комитет белгече гариза бирүченең вәкаләтләрен раслаучы документларны һәм гариза бирүченең вәкиленең шәхесен ачыклаучы документның булуын тикшерә.

54. Төзүче тарафыннан тәкъдим ителгән документларның төп нөсхәләрен кабул иткәндә, Башкарма комитет белегече аларның күчермәләрен ала һәм аларны үзенең имзасы һәм “күчермә дөрес” штампы белән раслый.

55. Башкарма комитет белгече төзелешне тәмамлау турында хәбәрнамәне вазыйфаи йөкләмәләренә керә торган корреспонденцияне кабул итү һәм теркәү кергән Башкарма комитетның оештыру-кадрлар секторы белгеченә (алга таба – керә торган корреспонденция буенча белгеч) тапшыра.

Керә торган корреспонденция буенча белгеч хәбәрнамәне, электрон формада алып барылучы керә торган корреспонденция журналында терки.

